Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Тайсуган авыл Советы

КАРАР

20 май 2025 ел №119

Әлмәт муниципаль районының Тайсуган авыл Советы «Әлмәт муниципаль районының Тайсуган авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 45 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә, шулай ук хокукый мониторинг тәртибендә

Тайсуган авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл Советының «Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 45 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл Советының 2018 елның 5 декабрендәге 49 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 9 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 53 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 59 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 106 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары» (алга таба- Тәртип) кушымтасының I бүлегенең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Башлыкның, башлык урынбасарының хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме ай саен акчалата бүләкләүне түләү өлешендә хезмәт өчен түләүнең уникенче төркеменә кертелгән муниципаль берәмлекләр башлыклары өчен

елына 15,48 айлык акчалата бүләкләүне, аларның урынбасарлары өчен елына 15,387 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә торган нормативтан артыграк була алмый.»;

1.2. тәртипнең II бүлегенең 6 пунктындагы 5 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент»сүзләренә алмаштырырга;

1.3. таблицу карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (Хезмәт өчен түләүнең 12 төркеме) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 21 083 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 20 468» |

1.4. карарга 2 нче кушымтада таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме (Хезмәт өчен түләүнең 12 төркеме) |
|---|---|
| Башлык | 21 091 |
| Башлык урынбасары | 15 391» |

2. Әлеге карарны Тайсуган авылы, Сәләхетдинов урамы, 36б йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Тайсуган авыл
җирлеге башлыгы М.Ф.Мостафин